ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ПЕСӘЙ
ТОРАК ПУНКТЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ
КАРАР

14.11.2025 ел № 2

2026 елда Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы Песәй
авыл җирлегенең Песәй авылында
гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» » 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге башлыгының “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” 2025 елның 1 ноябрендәге 5 нче номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. «2026 елда Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым акчаларын I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, Россия Армиясенә сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан 500 сум күләмендә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итеп, кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

«1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (авыл эчендәге юлларны ремонтлау (Тукай урамында ясалма тигезсезлек урнаштыру, Мичурин, Чишмә, Тукай, Дала урамы, Дала тыкрыгында вак таш, асфальт валчыклары сатып алу, Песәй авылындагы юлларны кардан чистарту);

2) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (МТЗ 82 тракторы өчен роторлы чапкыч сатып алу, төзекләндерү элементларын буяу өчен буяулар сатып алу, агачларны кисү, Песәй авылындагы мәдәни мирас объектын (мәчетне) әйләндереп алу өчен материаллар сатып алу);

3) һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү һәм ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Песәй авылында һәйкәлне күчерү, урнаштыру);

4) узган елларның калган өлешләрен юлларны кардан чистартуга юнәлтү.»?

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru "Песәй авыл җирлеге" бүлегендә бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге башлыгы ____________ В.И.Мөхәммәтгалеев